КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 июль г.Казань № 581

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 декабрь, 973 нче карары үз көчен югалткан дип санау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 502 нче; 2017 ел, 31 март, 203 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 807 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 973 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

2.1 нче пунктта:

«юридик һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

«физик затлар» сүзләренә кадәр «, яшәү урыны яки Татарстан Республикасы территориясенә килү урыны буенча теркәлгән» сүзләрен өстәргә;

4.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Конкурста катнашуга заявкада бәйсез экспертның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны турында белешмә, эш урыны, кредит оешмасындагы исәп реквизитлары, бу Тәртипнең таләпләре нигезендә бәйсез экспертиза турында мәгълүматлар булырга тиеш.»;

4.7 нче пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

дүртенче абзацта «бәяләмәләр күчермәләре» сүзләреннән соң «. Әгәр дә бәяләмәдә коррупциячел факторга, шулай ук аны бетерү ысулына күрсәтмә булмаса, мондый бәяләмә карауга кабул ителми;» сүзләрен өстәргә;

4.8 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тапшырылган документлар бу Нигезләмәнең 4.6 нчы һәм 4.7 нче пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);»;

бишенче абзацта «бу Нигезләмәнең 2.2 нче пункты белән билгеләнгән» сүзләрен «бу Нигезләмәнең 2.1 нче һәм 2.2 нче пунктлары белән билгеләнгән» сүзләренә алыштырырга;

4.10 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ике һәм аннан да күбрәк бәйсез экспертлар тарафыннан эчтәлеге буенча охшаш бәяләмәләр бирелгән очракта, конкурс комиссиясе тарафыннан бәя бирү өчен датасы буенча беренче бәяләмә кабул ителә, шулай ук бәяләмәләрнең даталары да туры килгәндә бәя бирү өчен мондый бәяләмәләрнең берсе дә кабул ителми.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 декабрь, 973 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Норматив хокукый актларга
һәм норматив хокукый
актлар проектларына
коррупциягә каршы бәйсез
экспертиза үткәрү буенча
экспертларның ел саен
үткәрелә торган республика
конкурсы турындагы
нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 23 июль, 581 нче
карары редакциясендә)

Форма

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында катнашуга экспертлар
заявкасы

1. Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булган очракта): ________________________________________
______________________________________________________________________________

2. Яшәү урыны адресы (килү урыны адресы): ____________________________________
______________________________________________________________________________

3. Паспорт мәгълүматлары: ______________________________________________________
______________________________________________________________________________

4. Эш урыны: ___________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

5. Гариза бирүчене норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча эксперт буларак аккредитацияләү турында таныклык номеры: ____________________________________
______________________________________________________________________________

6. Гариза бирүченең кредит оешмасындагы исәп реквизитлары: ___________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

7. Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче ел дәвамында Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары яки аларның вазыйфаи затларының муниципаль норматив хокукый актларына, әлеге хокукый актлар проектларына үткәрелгән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча

җибәрелгән бәяләмәләрнең (алга таба – бәяләмәләр) гомуми саны турында мәгълүматлар: ____________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

8. Бәяләмәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җибәрелгән мотивлаштырылган җавапләрдагы гариза бирүче тарафыннан ачыкланган, нигезле дип танылган коррупциячел факторларның гомуми саны турында мәгълүматлар: ______________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

9. Ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү буенча бәяләмәләрдә тәкъдим ителгән ысуллар турында мәгълүматлар: _____________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Бу заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

1) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча эксперт буларак аккредитацияләү турында таныклык күчермәсе;

2) ачыкланган коррупциячел факторларны һәм аларны бетерү ысулларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2011 ел, 21 октябрь, 363 нче боерыгы белән расланган форма буенча бәяләмәләр күчермәләре ____ санда ___ биттә;

3) бәяләмәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының мотивлаштырылган җаваплары күчермәләре _____ санда _____ биттә.

Бу заявкада, шулай ук аңа теркәлгән кушымталарда бирелгән барлык мәгълүматның дөрес булуы турында белдерәм.

_____________________________/_________________________________/
(имза) (Ф.И.Ат.ис.) (соңгысы – булганда)

Мин «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

_________________________/ _________________________________________/
(имза) (Ф.И.Ат.ис.) (соңгысы – булганда)

Дата: ___________________

____________________________________